**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 406 «20» 07 2020 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 449-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

1.1. «2017 елның 28 февралендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»

1.2. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 28 февралендәге 99 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуларны тикшереп тору тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 мартындагы 139 номерлы.

1.3. ««Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау хакында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан 2020 елның 20 февралендәге 112 номерлы

2.Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин